

Битараф булмаган хатын-кызлар очен чит балалар юк, шуна кvрә кон саен Мордовиянен торле-тор-ле почмакларында махсус хәрби операция зонасында булган егетләр очен маскировка челтәрләре vрәләр, гуманитар ярдәм кvрсәтәләр.     Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе сизгер һәм ярдәмчел укучылары гуманитар ярдәм жыю кысаларында хәрбиләргә ярдәмнәре чын патриотизм vрнәге. Мәктәп зур изге эш урынына әйләнгән. Уртак тырышлык белән укучылар, педагоглар һәм ата-аналар Ватаныбызны фронтта саклаучылар очен гуманитар ярдәм жыйганнар. «Батырлык тартмасы» хәйрия акциясендә дә актив бул-ганнар. Болар ярдәм акцияләре генә тvгел, бу безнен барыбызнын да тынычлыгы очен vз гомерен куркыныч астына куйган һәр солдатка безнен уртак кайгыртучанлыгыбыз һәм рәхмәтебезнен чагылышы.



Ә Инвалидлар коненә багышланган «Без яшәгән донья» акциясе кысаларында Татар Тавла авылы житәкчесе Рафик Исмәгыйль улы Абузяров, авыл китапханәсе модире Рима Фатих кызы Байгельдина, авыл клубы модире Зухра Равил кызы Абузярова, авыл активы белән берлектә, патриотизм һәм ихтыяр коче очен Илгиз Рәшит улы Абдюшевка (кvрv сәләте буенча инвалид) рәхмәт белдерәләр. Рәшит улы Илгиз беренчеләрдән булып волонтер була, физик чикләvләренә карамастан, ул кон саен диярлек авыл клубы бинасында маскировка челтәрләре vрешә. Рафик Исмәгыйль улы Абузяров ана, кvрсәткән ихтыяр коче һәм Ватанны саклаучылар очен ярдәме очен, Рәхмәт белдергән һәм Илгиз Рәшит улы Абдюшевка Саранскта гы Рухи-Мәдәни vзәк атап жибәргән бvләк белән бергә Татар – Тавла авылы администрациясе истәлекле бvләген тапшырган.



- Физик житешсезлек кvнел тошен-келегенә сәбәп тvгел, - ди Рәшит улы Илгиз.
Ул тулы тормыш белән яши һәм һәр коненә шатлана: республика олкәсен-дә оештырылган чараларда актив катнаша, ә спорт олкәсендәгеләрдә (армреслинг, остәл

теннисы) - берен-челәр рәтендә.
Яна ел алдыннан шул ук районнын Черемиш топ мәктәбе укучылары, ата-аналары һәм укытучылары тарафыннан махсус хәрби операция зонасында булган егетләр очен жыелган гуманитар ярдәм - чәй, оекбашлар, азык-толек, тәм-томнар, хатлар һәм 6 100 сум кvләмендә акча юллаганнар. Битараф булмаган якташларына кайгыртучанлыклары һәм ярдәм итvләре очен чын кvнелдән рәхмәт: әлеге ярдәм һәм жылы сvзләр безнен егетләр очен бик моһим, читтә калмаган һәркемгә рәхмәт, диләр оештыручылары.
Урнашылган гадәт буенча, Дубенка районы Ломат авылынын туган якны ойрәнv музеенда, Мязидә Якуб кызы Муракаева житәкчелегендә Рәзимә Таиб кызы Рахметуллова, Наилә Сабир кызы Рустамова, Тякия Абдулхак кызы Мусина, Сафия Хамзә кызы Филлипова, Танзилә Айса кызы Пикеева, Фавзия Бари кызы Мусина, Альмира Бари кызы Раимова, Газимә Фәрит кызы Фахретдинова, Мәуза Ибрагим кызы Хабибуллова маскировка челтәрләрен vрvне дәвам иттерәләр. Алар vргән һәр маскировка челтәре - ул тукыма кисәге генә тvгел, бу тормышны коткару, безнен Ватанны саклаучы сугышчыларыбызга ярдәм. Коннән-кон ярдәмнен торлеләре арта бара.




Ничә ел беррәттән, Мордовиянен башка районнары кебек vк, Кадошкино районы махсус хәрби операциядә катнашучыларга зур ярдәм кvрсәтә. Битараф булмаган кешеләр бергәләп маскировка челтәрләре һәм костюмнар vрәләр, коры ашлар әзерлиләр, безнен балаларга жибәрv очен башка гуманитар ярдәм жыялар. Шулай, Ла-тышовка урта мәктәбенен озайтылган кон группа укучылары, ГПД тәрбиячесе Нажия Фәрит кызы Вяльшина житәкчелегендә, СВО сугышчылары очен маскировка челтәрләре vрv акциясендә актив катнашалар. Ә Большие Поляны авылы жирле мәдәният йортында кон саен тукыма кыштырдавы, тупланып сойләшкән тавышлар, татар телендә жырлар янгыравы ишетелә. Авыл халкы бер моһим максат - СВОда катнашучылар очен маскировка челтәрләре vрv очен берләшкән. Изге эштә яше-карты катнаша. Битараф булмаган хатын-кызлар, ир-атлар челтәр vрә, ә Рафаэль Ибраһим улы Долотказин vзенен авто-транспортында Кадошкинога бушлай челтәрләр, гуманитар ярдәм ташый. Торкемдә катнашучылар vрv белән генә шогыльләнмиләр. Аларнын эшендә тагын бер юнәлеш - акча жыю һәм шул акчага гуманитар ярдәм итv. Алар, махсус хәрби операция зонасына жибәрv очен, жыелган шәхси иганә акчаларына, кирәкле ботен нәрсәне сатып алалар. Авылдан азык-толек, медикаментлар рәвешендә ярдәм берничә мәртәбә жибәрелгән. Бу эштә Большие Поляны авыл администрациясе һәм авыл кешеләре даими рәвештә зур ярдәм кvрсәтәләр. Ә тагын алар коры ашлар әзерләvчеләргә булышалар - vз бакчаларында vс-терелгән бәрәнге, яшелчәләрне Кадошкинога илтәләр. Торкемдә

катнашучылар «Фронтка ярдәм очен» медале белән бvләкләнделәр. Ике ел дәвамында торкемгә хәрби частьлардан Рәхмәт хатлары, торле грамоталар тапшырылган.
- Ышанабыз һәм беләбез: жинv безнен кулда булачак! Сугышчыларыбызга тизрәк ойләренә кайтуларын телибез! Ә хәзергә vз эшебезне дәвам итәбез, - диде Большие Поляны авылында гомер итvче Адилә Закир кызы Альмяшева. Шулай булачагына барыбыз да ышана.

**Наилә НАСЫРОВА**